

Быел күп кенә әдәбият, ижат кешеләренен юбилейлары. Шуна без мәдәният битендә юбилярларыбызны искә алабыз. Белгәнебезчә, апрельдә Габдулла Тукаебызга 140 ел иде, 1 майда танылган совет һәм Россия педагогы, хөрмәтле якташыбыз Мирза Мәхмvтовнын тууына 100 ел тулуын билгеләп vттек. Ө бvген Татарстаннын халык артисты Габдулла Рәхимкуловнын тууына 18 майда 100 ел тулу унаеннан анын тормышы һәм ижаты турында сойлибез.      Танылган жырчы 1926 елнын 18 маенда Татарстаннын Чvпрәле районы Keче Шәйморза кvп балалы гаиләдә туып vсә. Кечкенәдән жырларга ярата. Мәктәптә укыганда торле сәнгать чараларында актив катнаша. Ул 1943 елда сугышка алына, ил чигендә хезмәт итә. 1944 елда аны Молдавиянен Измаил шәһәреннән Батумига кvчерәләр һәм ул анда Хәрби жыр һәм бию ансамбленә билгеләнә.
1950 елда ул Магнитогорск шә-һәрендә училище тәмамлап, тау токымнарын шартлатучы мастер таныклыгын ала һәм шахтада эшли башлый. Ләкин жырга, сәхнәгә булган мәхәббәт аны Магнитогорскида эшләп килvче татар драма тvгәрәгенә китерә, концертлар оештыруны башлап йори. «Шунда рәхәтләнеп жырладым, бәхетемә ирештем кебек тоелды, - дип искә ала Габдулла Рәхимкулов. – Аннары минем жырчы булып китvемә соекле жырчыбыз Рәшит Ваһаповнын да олеше зур. Анын бригадасы берничә мәртәбә Магнитогорскига концертлар белән килде. 1954 елда Казанга кайткач, Габдулла Рәхимкулов Татар дәvләт жыр һәм бию ансамбле хорында солист буларак vз эшчәнлеген башлап жибәрә. Бераздан ул эстрада бvлегенә кvчеп, vзенен концерт торкемен оештыра.
1961 елда ул Казахстанда эшләргә чакыру ала, анда бер ел эшләгәч, аны янадан филармониягә чакырып алалар. Жырчы vз ижатына бик таләпчән карый, яна жырлар ойрәнә, онытыла башлаган татар халык койләрен репертуарына кертә. Ул татар халык жырларын, Ростәм Яхин, Әнвәр Бакиров, Исмай Шәмсетдинов, Фасил Әхмәтов, Хоснул Вәлиуллин һәм башка композиторлар ижат иткән жырларны оста башкара. Анын репертуарында аеруча Сара Садыйкова әсәрләре кин урын ала. Композитор аларнын кайберләрен нәкь ана махсус ижат итә: «Бер гvзәлен сагынам чишмәнен», «Арча кичләре», «Балкый Шәйморза утлары», «Кайтыгыз торналар», «Керфегенә тамармын мин» - шундыйлардан.Профессиональ жырчы буларак, беренче сынауны Габдулла Рәхимкулов Татарстан тамашачылары алдында vтә, анын житәкчелегендәге концерт бригадасы республикабыз авылларында, шәһәрләрендә бик кvп концертлар бирә. Габдулла Рәхимкуловнын тавышы республикабыздан тыш, илебезнен торле сәхнәләрендә янгырый. Илнен кайсы почмагында гына булмасын – Урта Азиядәме, Себер кинлекләре, Урал таулары артында урнашкан шәһәр, авыллардамы, татар һәм торки халыклар яшәгән барлык жирләрдә дә аны vз итеп, шатланып каршы алалар. 1979 елда лаеклы ялга чыкса да, ул әле тагын унбиш ел буе vзенен концерт торкеме белән республика буйлап чыгышлар ясый. 1960-61 елларда Алма-Ата филармониясендә эшләп ала.
Габдулла Рәхимкулов гомеренен ахыргы коннәренә кадәр сәхнәдә жырлаудан туктамый.

1997 елнын 9 октябрендә Габдулла Рәхимкулов йорәк оянәгеннән vлә.

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде**